# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"22" ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2020 елның 22 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Чишмәле Сап торак пунктында балалар уен мәйданчыгына җиһаз алу һәм урнаштыру;
2) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
   - Чишмәле Сап авылында Һәйкәлне койма белән әйләндереп алу өчен төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;
   - Чишмәле Сап авылы территориясендә куаклар, агачлар кисү һәм чистарту;
3) Пожар куркынычсызлыгы беренче чараларын булдыру:
   - Чишмәле Сап авылында пожар гидранты урнаштыру өчен тозелеш материаллары, җиһаз алу, хезмәте өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыенның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 225 (ике йөз егерме биш) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан граҗданнар саны 157 (бер йөз илле җиде) кеше, бу 70 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 157 (бер йөз илле җиде) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. "Сез 2021 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Чишмәле Сап торак пунктында балалар уен мәйданчыгына җиһаз алу һәм урнаштыру;
2) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
   - Чишмәле Сап авылында Һәйкәлне койма белән әйләндереп алу өчен төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;

- Чишмәле Сап авылы территориясендә куаклар, агачлар кисү һәм чистарту;

3) Пожар куркынычсызлыгы беренче чараларын булдыру:

- Чишмәле Сап авылында пожар гидранты урнаштыру өчен тозелеш материаллары, җиһаз алу, хезмәте өчен түләү мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.